**Татарстан Республикасы**
**Арча муниципаль районының**
**Арча шәһәр муниципаль берәмлеге**
**Арча шәһәр**
**башкарма комитеты**
**422000, ТР, Арча ш., Совет мәйданы, 27**
**тел. 3-15-25, 3-12-35**

**Муниципальное образование**
**город Арск**
**Арского муниципального района Республики Татарстан**
**исполнительный комитет**
**города Арск**
**422000, РТ, г.Арск, площадь Советская, 27**
**тел. 3-15-25, 3-12-35**

---

# КАРАР

**« 24 » апрель 2023 ел** **№ 70**

**«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләре таләпләрен үтәү буенча муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча административ регламентны раслау турында» Арча шәһәре башкарма комитетының 2020 елның 10 сентябрендәге 97 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы Федераль законны, «Россия Федерациясе субъектларында иҗтимагый хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» 21.12.2021 елгы 414-ФЗ номерлы Федераль законны, Татарстан Республикасының Административ хокук бозулар турында кодексын, Арча муниципаль районы “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге уставын гамәлгә ашыру, Төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү өлкәсендә контрольне көчәйтү өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Арча шәһәре башкарма комитеты карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләре таләпләрен үтәү буенча муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча административ регламентны раслау турында» Арча шәһәре башкарма комитетының 2020 елның 10 сентябрендәге 97 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләре таләпләрен үтәү буенча

муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча административ регламентка түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.7.1 пунктның 7 пунктчасы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) Россия Федерациясе Президенты каршындагы эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилне яки Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) каршындагы эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилне тикшерүдә катнашуга җәлеп итәргә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Арча шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Арча шәһәре башкарма
комитеты җитәкчесе Р.Ф.Касыймов